# Татарстан Республикасы Азнакай район Советы
# КАРАРЫ

Азнакай шәһәре № 358-47 «16» июнь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2013 елның 05 февралендәге 215-32 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә килүче затларның һәм муниципаль учреждение җитәкчеләре тарафыннан Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы үтәлеше турында» карары белән расланган, Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы, Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

Азнакай район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2013 елның 05 февралендәге 215-32 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә килүче затларның һәм муниципаль учреждение җитәкчеләре тарафыннан Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы үтәлеше турында» карары белән расланган, муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәисе М. З. Шәйдуллин